РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Киекле ав. КАРАР

«09» март 2022 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге
Киекле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Киекле авылы, Заречная урамы, 3А йорт адресы буенча урнашкан Киекле МФЦ бинасында 2022 елның 20 мартында 10 сәгать 00 минутта, элегрәк расланган:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 20.11.2021 ел, № 3;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 20.11.2021 ел, № 4 карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Киекле авылында яшәүче гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла дип билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

««Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Киекле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында элегрәк расланган 20.11.2021 ел, №3 һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены 20.11.2021 ел, №4 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертү белән килешәсезме:

Киекле авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, түбәндәге эш төрләре

буенча 2022 елда үзара салым тәртибендә 1000 сум күләмендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган эшләр исемлегенә өстәргә:

- Киекле авылындагы өч зиратны төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту өчен товарлар (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр) сатып алу (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу, койманы буяу, керү юлларына вак таш салу).

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И. Кашапова